Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге

## Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Көлкәмәр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

27 ноябрь, 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең Көлкәмәр торак пунктында 2025 елның 27 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 60 (алтмыш).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 39 (утыз тугыз).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 35 (утыз биш).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 4 (дүрт).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә: «Сез, 2026 елда Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Көлкәмәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (автоцистерна сатып алу), торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Н.В. Морозов